СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

14.12.2016 с. Верхний Услон № 17-175

## Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Гамәлдәге законнардагы үзгәрешләр белән бәйле рәвештә, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты эшләнде, ул район Советы тарафыннан хупланды һәм гавамитыңлауларда район халкы белән фикер алышуның барлык кирәкле процедураларын үтте.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының 99-101 статьялары нигезендә, 2016 елның 17 декабрендәге гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып,

Югары Ослан муниципаль районы Советы

Карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставына 1нче кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставының яңа редакциясен расларга.
3. Әлеге карарны законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.
4. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән срокларда үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Советының Законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы М. Г. Зиатдинов

Югары Ослан муниципаль районы Советының
2016 елның «14» декабреннән
№ 17-175 карарына
1 номерлы кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. Уставның 7 статьясындагы 1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 11 пунктча өстәргә:

«11) «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру»;

1.1.Уставның 45 статьясындагы 7 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында" 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыра";

2. Уставның 11 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 77.1 статья өстәргә:

«Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар экспертизасы»

«1. Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыруны нигезсез кыенлаштыра торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында Районның җирле үзидарә органнары тарафыннан район башкарма комитетының муниципаль норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы законы нигезендә экспертиза узарга тиеш.»;

3. Уставның 11 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 77.2 статья өстәргә:

«Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычларны билгели торган яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны үзгәртә торган муниципаль хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү»

1. Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычларны билгели торган яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны үзгәртә торган Районның муниципаль хокукый актлары проектлары, Татарстан Республикасы законы нигезендә, Район башкарма комитетының муниципаль норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә Районның җирле үзидарә органнары үткәрә торган җайга салу йогынтысын бәяләүгә түбәндәгеләр керми:

1) җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләүче, үзгәртүче, туктатып торучы, юкка чыгаручы муниципаль берәмлекләр вәкиллекле органнарының норматив хокукый актлары проектлары;

2) бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль берәмлекләр вәкиллекле органнарының норматив хокукый актлары проектлары.

2. Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен артык бурычлар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә этәрә торган нигезләмәләрне, шулай ук эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектларының һәм җирле бюджетларның нигезләнмәгән чыгымнары барлыкка килүгә ярдәм итә торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында уздырыла».

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы М. Г. Зиатдинов